Продолжение на стр. 5-6





Продолжение. Начало на стр.4

**«Без табиблар түгел, сәяхәт итәбез, зур шатлык хәбәрен – безгә Аллаһның бөтен дөньяга рәхмәте булган Хак илчесе – Пәйгамбәр (с.г.с.)нең килүе хакында сөенеч татартып йөрибез. Менә таягы, менә чалмасы, биргән кара савыты. Шунда Идел суларын, чишмә суларын салыйк та, бергәләшеп дога кылыйк, сез дә кушылагыз, Ислам динен кабул итегез, Аллаһның һидаятенә ирешегез», - дигәндә, «Укып карагыз, аннары карарбыз» - диләр.** Укый башладылар, кара савытына мондагы чишмәләрнең суларын тамчы-тамчы җыеп, Иделдән дә салып. Алларына Пәйгамбәрнең (с.г.с.) таягын куйдылар, башларына чалмасын чорнадылар да, тотындылар зикер әйтергә, Аллаһга ялварырга. Шул сәгатендә таяк каен яфрагы яра башлады. **Күрмәдек, ләкин ышанабыз. Галимнәребез барсын җентекләп язган. Шул каен агачыннан себерке ясап: «Кызны күтәреп мунчага алып керегез, чабындырыгыз», - дигәннәр. Мунчадан үз аягы белән чыгып: «Әтием, кабул итик бу динне. Хак илче ул! Бу бәләдән дә котылдым», - дигән. Айдар-хан да, янындагылар да Ислам динен кабул итә башлап, бу вакыйгадан өч йөз ел үткәннән соң, Багдадтан алты меңгә якын илчеләр, алар арасында остазлар, төзүчеләр Булгарга килделәр. Алар Булгарга якын Мораса авылына (остазы гәзизем Әхмәд Зәки хәзрәт авылы янындагы җәйләүгә) 922 елның майның 13-14-ләрендә килеп җиттеләр. Шунда аларны Алмуш-хан хәзрәтләре, Сәлкихан (Шилки) улы, Булгар иленең падишаһы каршы алды, аларның өсләренә алтын-көмеш тәңкәләр, бодай-арпалар сиптеләр, шатлыксөенечтән. Киңәшеп, бөтен Булгар әһеле, халкы: «Бөтенебез үз теләк-ихтыярыбыз белән, Аллаһның насыйп итүе белән, иманлы дәүләт дип Булгарны игълан итәбез, дәүләт дине, конституция иттереп Коръән-Кәримне кабул итәбез», диделәр. 16 май – 16 мөхәррәм, 310 хиҗри ел, 922 миләди ел. Ибн Фазлан яза: «Әйткән тәкъбирләрдән күкләр тетрәрлек булды».**

**Ел саен шушында киләбез. Өзелгән вакытларыбыз да булды. Монда кертмәскә азапланган вакытлар да булды, ләкин туктамадык!!!**

Бүген Россия белән бөтен ислам дөньясы берлектә. Кичә, өченче көн, күп илләрдән Казанга дин-мөбиндә газиз кардәшләр килделәр. Россия белән ислам дөньясы бергә, аннары Һиндстан, Кытай, Бразилия да кушылды, дәҗҗалга каршы дигән ният белән. **Җир йөзендәге халыкның 66 проценты, Аллаһны бар дип белгән, без сугыш чукмарлары түгел, тыныч, имин яшисебез килә, дип БРИКС дигән оешмада берләште!**

Америка, бөтен Европаның азгыннары, алар да бит Аллаһның бәндәләре, Пәйгамбәр (с.г.с.)нең өммәте. Оныттылар аны. Без дә искә төшермәдек, аларны дошман тоттык. Алар белән дошман булырга түгел, иң беренче безнең галимнәребез яңылышты, моннан берничә йөз ел элек, «Без – Ислам дөньясы, алар – дошман дөньясы», дип. **Дошман дисәң, үзеңнең бертуган абыен да, кардәшең дә дошман була, пычагын, коралын янында тота, җае килсә рәтләп куя. Безгә Иблистән башка дошман юк! Бөтен дөнья безгә дус, без дә – дус. Үзебезнең илдә христианнар белән кода-кодагый булып беттек. Татарстанда, Башкортостанда өчтән бер өлеше балаларыбыз уртак, оныкларыбыз уртак, илебез уртак. Бу илне без сайламадык, Аллаһ Раббүл Гыйззә насыйп итте.**

Камчаткалардан алып Париж, Лондонларга тиклем безнең атлы гаскәрләребез барып җитеп, Берлинны 80 ел моннан элек тетеп кайттык. Алар тагы терелде, елан шикелле. Коерыгына гына басырга түгел, башына бәрергә кирәк икән. Сугыш вакытында Америка, кем җинер икән дип, фашистлар Мәскәүгә барып җиткәнчегә кадәр бер гаскәр булып килгәннәр иде. Аннары союзникка әйләнделәр имеш. Берлинны бабаларыбыз алган вакытта, атом бомбаларын әзерләп, безнең илнең зур шәһәрләрен тетергә әзер иделәр. Аллаһ бирмәде.

**80 ел арасында аз булса да тыныч яшәдек.** Әмма бөтен дөньяны селкеделәр. Әфганстанга безнең гаскәрләребез керүе ни өчен булды? Әгәр кермәсәк, бөтен Европа, Америка кереп, тетеп бетерәләр иде ул, мескеннәрне. Чөнки Әфганстанның байлыгы триллионнар белән санала. Аннары Гыйрак, Ливия, Сирияны теттеләр. Ислам дәүләте төзибез, имеш. Ничә гасыр, хәтта Кытайны да талап яттылар. Хәзер дә шулай итәселәре килә. Сезнең, безнең догадан тора. Аллаһга ялварыйк. Аллаһ хур итсен үзләрен! Ләкин хур иткән вакытында, тәүфикъ, һидаятләрен бирсен. Хәзер килешә башладылар. Президентыбыз Владимир Владимировичның сигез шартын кабул иттеләр. Сугышмыйбыз, көзгә бетерәбез, Аллаһ бирса!

Окончание на стр. 6

Окончание. Начало на стр. 4-5

**«Кыямәтне Миннән башка беркем булдыра алмас. Сугыш чукмарлары дөньяны сугыш ялкынына салырга омтылган булсалар, Без аны сүндерәбез", - ди Аллаһ Тәгалә. Раббыбыз Аллаһ сүндерә! Үзе яраткан дөньяны беркемгә дә бетерергә бирми. Кыямәтнең хаклыгына ышанабыз. Ләкин кайчан булуын беркем дә белми. Пәйгамәр (с.г.с.) Җәбраил (г.с.)нән сораганда да: «Соралган зат сораучыдан артыгын белми», - ди.**

**Нигә бетерсен Аллаһ Үзе яраткан дөньясын. Ләкин бу дөньяга мәңгелеккә килмибез, вакытлы гомеребез!** Пәйгамбәр (с.г.с.): **«Минем өммәтемнең гомере алтмыш белән җитмеш арасында»,** - ди. Җитмешкә җиткәннән соң да, һәр көне мең елга тиң. Аллаһга шөкер, шөкер-ана кылсак утыз өч елы да, җитмеше дә, әзе дә, күбе дә, Аллаһны танып, бәндәсе булып яшәдең исә, дөнья-әхирәтең бер булачак, Аллаһ насыйп итсә. Шуның өчен шөкер-ана белән без дә тәкбирләребезне әйтик».

Шейх-уль-Ислам Талгат-хазрат молился на арабском и татарском языках, а тысячи единоверцев повторяли вслед за ним слова покояния, обращенные к Господу Миров: **«О Аллаһ! О Справедливый, Знающий все наши ошибки и недостатки! Прошу прощения за все свои ошибки в делах и словах… О Аллаһ! Поистине, нет Прощающего грехи, кроме Тебя! Прими же наше покаяние, прости нас и всех наших предков, которые покинули этот свет с истинной верой. Хвала Аллаһу, Господу миров! Пусть Всевышний примет нашу молитву!»**

Молитва покаяния «Тауба» – кульминация «Изге Болгар шөкер жыены» – всегда вызывает необыкновенный духовный подъем, окрыляет и вдохновляет, дарит надежду…

Торжественное открытие «Изге Болгар шөкер жыены» состоялось у Памятного знака. В нем приняли участие почетные гости: Раис РТ Рустам Минниханов; Шейх-уль-Ислам, Верховный муфтий, Председатель ЦДУМ России Талгат Сафа Таджуддин; председатель ДУМ РТ, муфтий Камиль Самигуллин; Митрополит Казанский и Татарстанский Кирилл; председатель ДУМ РФ, муфтий Равиль Гайнутдин и другие.

Говоря о том, что нынешний праздник «Изге Болгар шөкер жыены» проходит в Год защитника Отечества, Талгат Сафа Таджуддин отметил: **«Год этот будет продолжаться и не закончится, пока есть супостат, пока существует антихрист-даджаль. И мы всегда готовы! Мы видим, что происходит в мире. Мир нуждается в защите…»** Верховный муфтий рассказал о том, как 22 февраля 2025 года преподнес Президенту РФ Владимиру Владимировичу Путину символический подарок от имени миллионов верующих – боевой меч и щит защитника Отечества.

Талгат Сафа Таджуддин напомнил, что верующие должны соревноваться в добрых делах, в помощи сиротам, бедным, вдовам, нуждающимся, студентам; сотрудничать в благих делах и добродетели, и не сотрудничать во зле и вражде: **«Дьявол – наш единственный явный враг. Но мы его не боимся, ведь он лишь пастушья собака у Господа Миров. Если мы осознаем это, то райская жизнь еще в этом мире возможна! Мы приходим в него, плача от радости, что увидели свет, мать и отца, и через них познали Господа Миров. Разве это не радость?! Разве можно не радоваться жизни и обзывать эту же землю грешной? Не она грешная, это мы грешим, а земля плачет от распрей, раздоров и войн…»**

После официального открытия состоялся полуденный намаз на руинах древней Соборной мечети, под открытым небом, – еще одно высокодуховное действо, объединяющее единоверцев.

Праздник продолжился на спортивной площадке, где соревновались борцы куреш, и на ярмарке халяльных товаров.

В этот же день состоялась встреча глав региональных духовных управлений ЦДУМ России с Верховным муфтием Талгатом Сафа Таджуддином. За праздничной трапезой шел разговор о замечательном празднике «Изге Болгар шөкер жыены»; соратники и сотоварищи обменялись мнениями по многим вопросам, подвели некоторые итоги и наметили планы.



# НАЦИОНАЛЬНАЯ САМОБЫТНОСТЬ И РЕЛИГИЯ




17 мая в г.Казань прошло пленарное заседание XV Всероссийского форума татарских религиозных деятелей **«Национальная самобытность и религия»**. В нем приняла участие большая делегация ЦДУМ России во главе с Шейх-уль-Исламом Талгатом Сафа Таджуддином.

Выступающие на заседании говорили о путях сохранения языка, культурных и морально-нравственных ценностей. Были представлены региональные проекты, направленные на развитие национального самосознания и религиозного просвещения.

Шейх-уль-Ислам Талгат хазрат рассказал об истории принятия ислама нашими предками - булгарами и о том, что во всем исламском мире знают и почитают наших предков. В качестве примера привел историю посещения им Сирии, как только в 1980 году его избрали председателем ДУМ европейской части СССР и Сибири: «**В 1980 году мы совместно с Шейх-уль-Исламом Аллахшукюром хазратом Пашазаде участвовали в фотовыставке, посвященной жизни мусульман Советского Союза в Сирии.** Была зима, но, несмотря на холод, приходило очень много народа. В последний день нас принимал лидер страны Хафез Асад (президент Сирии с 1971 по 2000 год — прим. ред.), он стоя приветствовал нас и сказал: **«Добро пожаловать, потомки булгар, ваши предки укрепляли нашу веру»**, — вспомнил Талгат-хазрат Таджуддин. **«...Бүгендә горурланабыз гаскәрләребез, егетләтербез, имамнарыбыз белән. Менә яныбызда Гали хәзрәт - Ульяновск шәһәреннән утыра. Ун тугыз ярасы бар, егерме бер кыйпылчык (осколок) иде уң ботында. 2022 елның 23 февралендә ул беренче партия белән Белоруссия ягыннан махсус хәрби операция зонасына керде. Ни булганнарын телевизордан гына түгел, өстән беләбез. Башка имамнарыбыз да (бөтенесе вәгазь сөләп кенә түгел, ул да искиткеч олы нәрсә), шунда имам булып барып, контрактка кул куеп, сугышның үзендә катнашканнары да бар. Өчесе шәһид, Аллаһның рәхмәтендә булсыннар! Дошманны гына җиңеү түгел, үзләре шайтанны җиңделәр! Имамнар, батюшкалар бергәләшеп йөриләр, бергәләшеп вәгазь сөйлиләр, яугирләрнең барсы да «Бог - Один», ди. Тагы ни кирәк?!**

**Шуның өчен бу сугыш фикерләребезне, акылларыбызны, тәртипләребезне, әдәпләребезне үзгәртүгә олы бер этәргеч булачак. Бетәр сугыш!**

**Яңырак Бахрейнда, бөтен җир йөзендәге мөселманнарга баш мөфти сайланды. Ул да исә Мисыр Бөек имамы, «Әл-Әзхәр» университетының ректоры, шәех Әхмәд Әл-Тәйеб хәзрәтләре. Җитмеш биш илдән килгән делегатлар бу сайлауда катнашты.**

**Шуннан кайткан вакытта Мәскәүдә Президентыбыз Владимир Владимирович Путин белән очраштык. Ул да: «Бездә берләшеп, бергә булып, һичшиксез шул баш мөфтилеккә керергә тиешле. Безнең Россия мөселманнары гәйрәтле, илгә хезмәт белән дә, батырлык белән дә дан бирген, дөнья мөселманнарына да үрнәк булырлык дәрәҗәгез бар. Бергә булып, Россия мөселманнарының тавышы бөтендөнья халыкара аренада каты яңгырарга тиеш», - дигән сүзләрен әйтте. Аллаһ мөбәрәк кылсын бу мәҗлесләребезне!»**

После пленарной части работа продолжилась на дискуссионных площадках (**«Религиозная основа нашего народа – ханафитский мазхаб»**, **«Современное состояние халяльной индустрии»**, **«Любовь к Родине – часть веры»** и др.). Делегаты ЦДУМ России активно участвовали в работе секций: председатель РДУМ Кировской области, муфтий Зуфар Галиуллин выступил с докладом **«Значение мазхабов»**; преподаватель медресе «Хусаиния» Руслан Ахмеров подготовил сообщение **«Почему татарский народ придерживается мазхаба Абу Ханифы»**.



# ЗАСЕДАНИЕ ГРУППЫ СТРАТЕГИЧЕСКОГО ВИДЕНИЯ «РОССИЯ – ИСЛАМСКИЙ МИР»




**16 мая в г.Казань состоялось ежегодное заседание Группы стратегического видения «Россия – Исламский мир». Тема заседания – «Опыт России и стран исламского мира в сфере молодежной политики: общие вызовы и совместные действия».**

Заседание началось с чтения Священного Корана. Раис РТ Рустам Минниханов приветствовал участников ГСВ «Россия – Исламский мир» и почетных гостей, обратив внимание на актуальность обсуждаемой темы: **«Сегодня порядка 70% населения исламского мира составляет молодежь. Наш долг – привить подрастающему поколению бережное отношение к своей истории и культуре. Только так мы сможем сохранить свою идентичность и культурное многообразие». Заместитель Председателя Правительства РФ Марат Хуснуллин огласил обращение Президента РФ В.В.Путина к участникам саммита.**

Выступающие на заседании говорили о необходимости укрепления международных связей в сфере молодежной политики, о реализации обучающих программ, образовательных и исследовательских проектов, о проведении различных международных конференций и семинаров.

**Глава российской уммы Талгат Сафа Таджуддин обратился к слушателям с программной речью, в которой с позиций гражданина и патриота озвучил глобальные вызовы современности и пути решения важнейших мировых проблем**.

С заключительным словом к собравшимся обратился модератор заседания, заместитель Председателя Группы стратегического видения «Россия – Исламский мир» Марат Гатин.

## УТРАТЫ

# НА 84 ГОДУ ЖИЗНИ ЭТОТ МИР ПОКИНУЛ КАЗЫЙ УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ САВБЯН-ХАЗРАТ СУЛЕЙМАНОВ

Один из старейших муфтиев России Савбян хазрат Юнусович Сулейманов с 2002 по 2014 гг. возглавлял Региональное духовное управление мусульман Ульяновской области ЦДУМ России. Под его руководством было реализовано множество проектов, способствующих возрождению духовно-нравственных устоев, продвижению ценностей традиционного Ислама.

Проводы усопшего и джаназа-намазы прошли в трех местах, связанных с жизнью и деятельностью уважаемого аксакала. В мечети р.п.Чердаклы, построенной по инициативе Савбяна-хазрата в 1991 году, собрались жители Чердаклинского, Мелекесского и Новомалыклинского районов. В Центральной соборной мечети г.Ульяновск состоялся джаназа-намаз, в котором приняли участие: председатель РДУМ Ульяновской области, муфтий Ильдар Сафиуллин; председатель РДУМ Самарской области, муфтий Талип Яруллин; ректор Казанского медресе имени 1000-летия принятия Ислама Ильяс Зиганшин; жители города. Затем похоронная процессия направилась в с.Большой Чирклей Николаевского района. На завершающую прощальную церемонию в родное село Савбяна хазрата прибыли: Шейх-уль-Ислам, Председатель ЦДУМ России Талгат Сафа Таджуддин; многие имамы РДУМ Ульяновской области, односельчане, родственники покойного хазрата.

**Шейх-уль-Ислам Талгат хазрат перед женаза-намазом обратился к единоверцам с проповедью: «Газиз кардәшләрем, газиз милләттәшләрем, ватандашларым! Бүген без мәрхүм Сәүбән хәзрәтне бу ямьле дөньядан мәңгелек сәфәргә озатабыз.** Хәзер изге бәндәбез, Сәүбән хәзрәт, тыныч кына Аллаһ Раббыбызга таба кайту сәфәрен башлады.

Бүген, әле генә тагын да вафатларның хәбәрен ишеттек. Санкт-Петербургта Ягафәр хәзрәтнең җәмәгате Зәйтүнә абыстай таңда мәңгелек сәфәренә чыкты. Күпме бәлә-хәсрәтләр күрде, Ягафәр хәзрәтнең дөньядан үткәненнән соң, үз баласы анасын йортыннан куды, Аллаһ сакласын. Бәндә җир астына



үткән булса, нәтиҗәсе ни булыр, белмим. Шулай дөньяда! Аерылабыз!

Без моның Хак иканлеген беләбез. Бу дөньяга килдек командировкага. Дөньяның әчесен дә, төчесен дә күрергә. Дөньяның әчесен, төчесен күрмәсәк, Җәннәтнең кадерен дә белмәс идек. Кышны күрмәсәк, җәйне сагынмыйбыз, җәйне күрмәсәк, кышка җитә алмыйбыз. Шулай бу дөньяда Аллаһ Раббул-Гыйззә сыный!

**«Сөендер!»**, - ди Аллаһ Раббул-Гыйззә хәбибе саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә. Көч бир! Һәрбер дөньядагы сынауны күргән чагында: **«Иннә лилләһи вә-иннә иләйһи раджиун» —**

Азагы 11нче биттә

— إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ — **«Без барбыз Аллаһныкы, Аллаһны безне бар иткән** (бар иткән генә түгел, яраткан, яр иткән, сөеклесе иткән) **бәндәләребез... һәр минут, һәр секунд, һәр ай, һәр ел саен Аллаһ Раббыбызга кайтучыларбыз, кайту юлындабыз»**.

Ашыкмыйбыз, гомеребез кыска булса да. **Рәсул Әкрам (с.г.с.): «Минем өммәтемнең гомере алтмыш белән җитмеш арасында», - диде.** Атабыз Әдәм (г.с.) 950 ел яшәде. Иң әүвәл Аның ике улы арасында гауга чыгып, җир йөзендә беренче кан коелды. Аннары дүртәр йөз, аннары ике йөз, йөз сиксән ел яшәгән пәйгамбәрләр, халыклыр булдылар. Безгә үлчәнгәне – алтмыш белән җитмеш арасы. Пәйгамбәребез (с.г.с) 63 яшендә дөньядан узды. Бөтен өммәт елады. **«Ничек инде Аллаһның илчесе үлә?»**, - дип аптырауда калганнары да булды.

**Коръәндә язылган: «Син дә мәет, дөньяда булганнары бөтенесе мәетләр». Бер көн җитәчәк, Пәйгамбәребез (с.г.с.) үзе: «Бүген булганнарда йөз елдан соң берсе дә калмас», - диде. Аллаһның кануны шулай!**

Без барчабыз Аллаһның җир йөзендәге хәлифәсе. Шул вазыйфабызны үтәргә тиешлебез. Җимерергә түгел! **«Аллаһ Раббул-Гыйззә сезне бу дөньяда ямьле тормышлар өчен яраткан, никахлашыгыз, өйләнегез, балаларыгызны үстерегез, сезнең ишегез белән Кыямәт көнендә мин башка пәйгамбәрләр арасында данланырмын», - ди Пәйгамбәребез (с.г.с.)**.

Шундый гомерне мөхтәрәм Сәүбән хәзрәт тә үтте. Тормыш алтмыш белән җитмеш арасында дигәннән соң да, Аллаһ Раббул-Гыйззә тагын 14 елны яшәргә насыйп әйләде. Сиксән дүрт дисәк тә, аңарга ике ел ярым тагы кушыла, ай календаре белән - сиксән алты ярым була!

**«Сиксәнгә җиткән кешенең гонаһлары язылмас», - диде Пәйгамбәр (с.г.с.)**, булдыра алса да. Туксанга җитте икән, ул вакытында бәндә Аллаһның җир йөзендәге әсире була. Туксан - «тук» дигән сүз. **Якыннары, балалары, оныклары кадерен белеп, кадерләп карыйлар икән, Аллаһ Собханаһу вә Тәгалә йөзгә кадәр дә җиткерә. Йөзгә җиттең исә, яңа тешләрең чыга, чәчләрең дә каралана башлый. Йөз — «плыви дальше» дигәнне, мәңгелеккә йөз дигәнне аңлата.**

Аллаһ Раббул-Гыйззә бу мәрхүмебезне авыру-сырхаулары белән дә сынады. Әль-хәмдү лилләһ, ләкин Раббул-Гыйззә шушы яшенә җиткереп, шушы кадәр кардәшләре, хезмәттәшләре арасында, Аллаһга үтәгән хезмәтендә батыр булып, менә кияүе Ильдар хәзрәтне дә бу урынында калыдырып, балалары да – барсы да иманда, намазда...

**Арабызда Талиб хәзрәт тә бар. Әтисе Вагиз хәзрәт заводта эшләгән жиреннән, бер генә ел пенсияга чыгырга калган иде, дин-мөбинебезгә хезмәткә тотынды. Аллаһы Тәгалә аңарга да сиксәннән узырга насыйп әйләде. Һәркайсыбыз шушылай иттереп балаларыбызны җиткереп, артыбыздан нык иттереп атлый торган егетләр калдырырга тиешбез...**

Бу мәчетләрне кем төзеде? Сез! Ихласыгыз, тулы иманыгыз, Аллаһыдын олы өметләр белән! Башка милләтләр арасында булып та, башкаларга үрнәк булырлык. Батырлыкта да, ата-ананы хөрмәт итүдә дә, башыгыздагы чалмалар да, бүген Аллаһы Раббым Газраилны җибәргән булсада, кайтырга әзер икәнеңне күрсәтеп, арагызда булган шушы бердәмлек-татулыгыгызны, Сәүбән хәзрәт шикелле җаны-тәне белән, бөтен гомерен Аллаһның юлында йөреп, Аллаһның мөбәрәк диненә, газиз Ватаныбызга хезмәт итүдә үткәргән кешеләрнең дә кадерен тануыгыз шушында, ничә сәгаттән бирле көтүегез күрсәтә. Без сәгатенә ике йөз километрлап чаптык, артыгы белән дә, очтык фәрештәләр канатларында, әль-хәмдү лилләһ.

Сабырыгызга да, **Пәйгамбәребез (с.г.с.) әйтә: «Кем берәүнең, мөселман кардәшенең җеназасында катнашты исә, аннары каберенә кадәр озатты исә, дога кылып китте исә, ул бәндәгә Аллаһ Раббым кыйрат-кыйрат бирәчәк». Таулар кадәр әҗер-савабын насыйп итәчәк. Үзегезнең дә кадерегез артачак! «Җеназада кырык кына кеше була торган булса да, Җәһәннәмгә хөкем ителерлек дәрәҗәдә, кимчелек-хаталары булган булса да, ул бәндәнең бөтен гонаһларын Аллаһ Раббул-Гыйззә гафу итәчәк»**, - ди Пәйгамбәребез (с.г.с.). **«Чөнки сез Аллаһның җир йөзендәге шаһитләре». Шаһитләр кем, нәрсә икәнлекне, тирә-юнебездәге азгынлыкны да күрәбез. Шулай да юлыбыздан тайпылмыйча яшибез. Балаларыбызга, күршеләребезгә, башка милләтләргә, үзләрен башка диндә дип уйлаганнарга да үрнәк күрсәтеп яшәргә тырышабыз, Аллаһга шөкер!**

Ләкин дөньяда кайный бит. Мәскәүдә кичә генә Палестинаның илчесе белән күрештем. Көн саен йөзләгән балаларны, картларны, хатыннарны үтерәләр, шәһәрләрне җимереп бетерделәр, сәхрәгә чыгып, палаткаларда яшиләр. Рамазан башыннан бирле бер гуманитар ярдәмне дә үткәрмиләр. Миллионлаган кеше азаплана. Аларны ашатырга кирәк. Без дә җибәрдек ярдәм тонна-тонналап, хәләл консерваларын да, акчалата да, Аллаһга шөкер. Рамазанга хәтлем өчәр-дүртәр йөз машина үтәләр иде, хәзер берәү дә үтми, диләр. Россиядә Палестинадан 230-га якын студентлары укый, ата-аналарыннан килә торган ярдәмләре юк, илчелектән бездән ярдәм сорадылар. Ярдәм күрсәтик, кулдан килгәнчә, Аллаһ разый булыр.

**Соңгы юлына озатабыз хәзрәтебезне. Ләкин Аллаһ Раббул-Гыйззә мәңгелектә дә күрешергә насыйп әйләсә иде.**

**«Мине ишетеп, Мине күргәннәр – ишетмәгән, күрмәгәннәргә ирештерегез», - диде Рәсүле Әкрам (с.г.с.) саубуллашу хаҗында, Хаҗҗатуль-Үәдәгъдә!**

**Безнең бу дөньяда асыл вазыйфабыз – Аллаһга шөкер кылып, балаларыбызны иманлы, тәүфиклы, бәхетле итеп тәрбияләргә, бөтен тирәбезгә иман нурын чәчергә тырышырга, сүз белән дә, эш белән дә. Сүз белән кабул итмәсәләр, үрнәк белән аңлатырга тиешбез.**

Аллаһ разый булсын! Мәрхүмебез Сәүбән хәзрәтебез Аллаһның рәхмәтендә булсын! Аллаһ Раббым, Сәүбән хәзрәт белән дә бергәләшеп Аллаһ Рабыбызның дидар мәҗлесләрендә күрешүләребезне насыйп әйләсен! Туганнарына, балаларына, якыннарына күркәм сабырлык биреп, сезгә дә, безгә дә, бөтенебезгә дә хәер-дога белән, изгелек белән искә алуларыбызны насыйп әйләсә иде. Әссәләмү галәйкум вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтуһу!!!»












# ПОСЛЕДНИЙ ЗВОНОК В ДЕТСКОМ ДОМЕ




Руководство ЦДУМ России много лет шефствует над Центром содействия семейному воспитанию имени Шагита Худайбердина – это старейшее учреждение г.Уфа для сирот и детей, оставшихся без попечения родителей.

Верховный муфтий Талгат Сафа Таджуддин всегда приходит на «Последний звонок», чтобы поздравить юношей и девушек с началом нового этапа жизни. В этом году выпускной прошел в формате семейного вечера «Пока все дома». Шейх-уль-Ислам приветствовал воспитанников и сотрудников во главе с директором Фанисой Бадретдиновой, которая уже 21 год трудится на своем посту: **«У 12 детей – 12 прекраснейших созданий в этом году выпускной. Для вас этот дом был семьей. Теперь вы выходите в мир!»** Верховный муфтий поведал о 99 именах Аллаhа и об ангелах, которые всегда рядом с человеком, охраняют его от зла, и показал, как можно обращаться к Создателю: **«Всевышний – в сердце человека. Посмотрите внутрь себя и найдите Бога! Если вы Его правильно, искренне попросили, то в сердце загорится уголек...Поблагодарите Бога, и все, что загадали, исполнится... Связь с Ним возможна моментально! Это осуществляется и во время намаза. Наслаждайтесь благами, которыми Он нас наделяет...»** Шейх-уль-Ислам рассказал о роли веры в жизни воинов, участвующих в специальной военной операции, и о священнослужителях, имамах и батюшках, которые оказывают духовную поддержку защитникам Отечества. Завершая выступление, Верховный муфтий сказал: **«Счастья вам и благодати Всевышнего, и поддержки Его вашим родным и близким! Но прежде всего, сами старайтесь делать людям добро. Не разделяйте их по вере и нациям, Бог у нас Один, и Отчизна – держава наша одна. В добрый путь!»**

Директор Центра содействия семейному воспитанию имени Шагита Худайбердина Ф. Бадретдинова выразила искреннюю признательность Верховному муфтию за подарки выпускникам, за искреннюю заботу и вручила Благодарственное письмо, в котором отмечена его многолетняя помощь воспитанникам.

**Учредитель:** Центральное Духовное управление мусульман России
**Адрес редакции и издателя:** 450057, Республика Башкортостан, г. Уфа, ул. Тукаева, 50
**Тел:** (347)250-80-86, **Факс:** 250-80-99
**Главный редактор:** Зубаерова И.М.

**Уважаемые читатели! Относитесь с почтением к газете, не используйте ее в недостойных целях!**

**Сайт:** cdum.ru
**e-mail:** maglumat@cdum.ru
Дата выхода в свет: 25.08.2025
**Объем:** 12 полос **Тираж:** 2000 экз.
*Заказ №140*

Отпечатана в ООО Переплетная мастерская «Книга-принт» Адрес: 450106, г. Уфа, ул. Рабкорова, д. 2/7
Цена бесплатная.

*Газета издается при содействии и финансовой поддержке некоммерческого благотворительного «Фонда поддержки исламской культуры, науки и образования»*

Газета зарегистрирована в Министерстве РФ по делам печати, телерадиовещания и средств массовых коммуникаций, св-во ПИ №77-11980 от 04 марта 2002 г.